**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь, 2022 ел № 809

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 1 нче номерлы Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә Россия Герое Иван Алексеевич Додосов исемен бирү турында

Укучыларны патриотик тәрбияләү максатларында, 2022 елның 23 октябрендәге Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 1 нче номерлы Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе коллективының үтенечнамәсен карап Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 1 нче номерлы Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә Россия каһарманы Иван Алексеевич Додосов исемен бирергә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 1 нче номерлы Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе исемен түбәндәгеләргә үзгәртергә: - тулы исеме: Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Пестречинская средняя общеобразовательная школа №1 с углубленным изучением отдельных предметов имени героя России Ивана Алексеевича Додосова» Пестречинского муниципального района Республики Татарстан; Кыскартылган исеме: МБОУ «Пестречинская СОШ №1 им. И.А.Додосова». Тулы татарча исеме - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Россия каһарманы Иван Алексеевич Додосов исемендәге аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 1 нче номерлы Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе. Кыскартылган исеме: «И.А.Додосов ис. 1 нче номерлы Питрәч УГББМ» МБГББУ.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Россия каһарманы Иван Алексеевич Додосов исемендәге аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче 1

нче Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставын расларга.

4. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Россия каһарманы Иван Алексеевич Додосов исемендәге аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче 1 нче Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы Үтәгәнова Нина Ивановнага салым органнарында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Россия каһарманы Иван Алексеевич Додосов исемендәге аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче 1 нче Питрәч урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставын дәүләт теркәвенә алганда мөрәҗәгать итүче булырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. С. Шәйхесламовка йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин